| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

13.05.2025 п.г.т.Алексеевское № 261-р

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2025 ел, № 23-р «2025 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 23.01.2024 ел, № 63 Указы нигезендә Башкарма комитетның 27.01.2025 ел, № 23-р «2025 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» күрсәтмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.3 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә түләүсез кайнар азык ашатуны, иртәнге ашны тулы күләмдә оештырырга:

- составында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән белем алучылар өчен, өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген көндезге бүлектә гамәлгә ашыручы оешмада белем алу шарты белән, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе, уку урыныннан белешмә биреп, язма гариза нигезендә;

- составында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән, тәрбиягә алынган балаларны да кертеп, өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген көндезге бүлектә гамәлгә ашыручы оешмада белем алу шарты белән, Россия Федерациясе гражданлыгы булмаган, әмма Алексеевск муниципаль районы территориясендә яшәүче, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) балаларның туу турында таныклыкларының күчермәсен биреп язма гариза нигезендә;

- 18 яшькә кадәрге авыр тормыш хәлендә булган гаиләләрдәге балалар өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаиләдәге гаилә хәлен тасвирлап, гаризага гаиләнең көнкүреш яшәү шартлары актын кушып язылган язма гариза нигезендә, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе, сыйныф җитәкчесе һәм шушы җирлек башлыгы имзасы белән;

- составында өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы, тәрбиягә бала алган һәм опекун гаиләләреннән, тәрбиягә алынган балаларны да кертеп, өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген көндезге бүлектә гамәлгә ашыручы оешмада белем алу шарты белән, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән),

балаларның туу турында таныклыгы һәм опека һәм попечительлек бүлеге документларының күчермәсе белән, (балигъ булмаганга опека билгеләү турында карар) язма гариза нигезендә».

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ җитәкчесенә үзгәрешләр нигезендә укучыларны кайнар тукландыруны оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчан файдаланылуын тикшереп торырга (Н.А.Крохина).

3. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм 01.01.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О. Н. Леденцов**